ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«КАРКАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КЕРКӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

2024 елның 11 ноябре　　　　№ 5

Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 23 ноябренә Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Сез Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Керкәле авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, шулай ук I төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1)торак пункт территориясен төзекләндерү (триммер һәм бензопила өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (дизель ягулыгы, май, фильтр сатып алу);
тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү(территорияне коры-сары һәм

чүп үләннәреннән чаптыру, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү, урамнарны кардан чистарту һәм башка эшләр);

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны,транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, ремонтлау (суүткәргечләр төзү һәм ремонтлау, Керкәле авылы халкын эчә торган су белән тәэмин итү);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы Совет ур. 93 буенча үзидарә администрациясе бинасында, Совет ур. 45 буенча гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.И.Бигманов

ИНН 1649013364
КПП 164901001